

Идел буе федераль округында Боек Ватан сугышында Жинvнен 75-еллыгы унаеннан масштаблы акция старт алды.

«Безнен Жинv Коне» акциясе РФ Президентынын Идел буе федераль округы аппараты тарафыннан башлап жибәрелгән - жыр марафоны тобәк халкын бердәм халык коллективына бер ләштерә. Катнашучы тобәкләр эстафетаны бер-берсенә тапшыралар. Алар ин атаклы «Жинv Коне» жырын башкаралар. Бу жыр очраклы гына сайланмаган, автор-композитор Давид Тухманов һәм шагыйрь Владимир Харитонов - халык батырлыгынын боеклеген һәм каһарманлыгын кvрсәтә. Боек бәйрәмнен гимнына әверелгән жыр очен быел юбилей елы - беренче тапкыр ул нәкъ 45 ел элек янгырады. Акциягә Мордовиядә һәм Россия шәһәрләрендә яшәvче якташлар да кушылды. Яраткан «Жинv Коне» жырыннан тыш, алар сугыш еллары жырларын да башкаралар, шигырьләр укыйлар. Ойдәге роликларны язып, интернет челтәрләрендә урнаштыралар, фикерләр жыялар.

Мордовия Республикасында жыр марафоны февраль башында старт алды. Танылган жырны Саранск һәм муниципаль районнарнын ин яхшы ижат коллективлары, халык һәм атказанган артистлары, яшьләр, волонтерлар һәм патриотик берләшмә әгъзалары башкаралар. Алар эстафетаны кvршеләренә тапшыра.

Милли республикаларга vз туган телләрендә легендар жырнын куплетларын башкарырга тәкъдим ителде. Рус, мокша, әрзә телләрендә «Жинv Коне»н башкарып, халык патриотик акциясен башлап жибәрде. Бу жырны татар телендә «Умырзая» дигән халык жыр һәм бию ансамбле башкарачак.

Боек Ватан сугышында Жинvнен 75- еллыгы унаеннан оештырылган «Безнен Жинv Коне» жыр марафоны безне - Идел буе федераль округында яшәvчеләрне Хәтер һәм Дан елында берләштерә.

Наилә НАСЫРОВА